# Проект эше

## Рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә уен технологиясен кулланып,фигыль сүз төркемен өйрәнү

Башкарды:

Максудова А.М. –Бакырчы урта мәктәбе, Тәтеш районы.

# Теманың актуальлеге

- Алган белемнәрне актуальләштерергә ,үз фикерен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, укыту  һәм тәрбиянең бердәмлегенә ирешүдә уеннарның кирәклеге сизелә.
- Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар һәм уен элементлары укучыларны активлаштыра,аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә,иҗади халәт тудыра.
- Туган телгә мәхәббәт,кызыксыну тәрбияли

# Максат һәм бурычлар

- Рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә  фигыль сүз төркемен өйрәтүдә уен технологиясенең ролен күрсәтү,бу алымнарны куллану үзенчәлекләрен билгеләү тора.
- Балаларга белем бирүнең бер элементы буларак, материалны үзләштерүдә куллану
- Теманы үзләштерүдә уенның әһәмиятен билгеләү, өстенлеген ассызыклау

# Проектның фәнни-гамәли әһәмияте

- Уен технологиясенең  методикасы,эшне оештыруда уеннар турында теоретик мәгълүмат тупланган,методик күрсәтмәләр китерелгән.
- Хезмәттә  тупланган материалларны методик  ярдәмлек буларак  тәкъдим итеп була.

# А.С.Макаренко- бөек педагог

- “Яхшы оештырылган  уен әйбәт эшкә охшый...Һәрбер уенның нигезендә барыннан да элек,хезмәт тырышлыгы,фикер тырышлыгы бар”
- Уен вакытында баланың игътибары ныгый,акылы үсә, физик яктан чыныга.
- Оялчан балаларны да “уятырга “мөмкин.

# Уеннарның төркемнәре

- Беренче чиратта уеннарны эшчәнлек төре буенча берничә зур төркемгә бүлеп карарга кирәк: *хәрәкәтле уеннар, интеллектуаль уеннар, психологик уеннар, иҗтимагый уеннар.*
- **Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә** түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин: *дидактик уеннар (бу төр уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән), тәрбияви уеннар, иҗади уеннар, коммуникатив уеннар.*
- **Үткәрү методикасы буенча уеннар** бик күп төрләргә бүленә: *предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.*
- **Төрле фәннәргә бәйле рәвештә уеннар** берничә төргә бүленә: *математик уеннар, химик уеннар, физик уеннар, экологик уеннар, музыкаль уеннар, әдәби уеннар, спорт уеннары һ.б.*
- Уеннар яңа теманы үзләштерү, белемнәрне ныгыту, гомум уку күнекмәләрен формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерүдә куелган бурычларны уңай хәл итүдә зур мөмкинлекләргә ия.

# Уен кулланып, яңа темага керү

- **Уку мәсьәләсен кую.**
- 1) -Дәреснең темасын белү өчен, безгә кроссворд чишәргә кирәк булыр.
- 1. Хәрефләрнең билгеле бер тәртибе нәрсә дип атала? (алфавит)
- 2. Алтыдан соң килгән сан. (җиде)
- 3. Өч кат тун кигән.-
- Кем салдырса, шул җылый. (суган)
- 4. Барысын да ашатам, ә үземнең авызым юк. (кашык)
- 5. Бу эчкелтем җимешне чәйгә салып эчәләр.
- 6. Кышның соңгы ае. (февраль)
-
- -Горизонталь буенча нинди сүз килеп чыкты? (Фигыль)
- - Димәк, без алга таба нинди теманы үзләштерүне дәвам итәбез? (Фигыль)

# Эш тәҗрибәсеннән

- -Укучылар, хәзер без сүзләр дөньясына сәяхәткә чыгарбыз. Сәяхәткә чыгу өчен безгә бу рәсемнәр буенча хәрәкәтне, эшне
- белдергән сүзләр әйтергә кирәк.
- -Без нинди сүзләр әйттек?
- -Алар нинди сорауларга җавап бирәләр?
- -Димәк, нинди сүзләрне кабатларбыз?
- -Фигыльләрне.
- -Әйдәгез, фигыльнең билгеләмәсен искә төшерәбез.
- (Укучылар билгеләмәне әйтәләр; таблица буенча да укып китәбез).
- -Укучылар, бүген сәяхәттә түбәндәге тукталышлар булыр:
- 1) «Мәкальләр аланы».
- 2) «Барлык һәм юклык».
- 3) «Заманнар».
- «Зат – сан белән төрләнеш».

# “Күршеләр уены”

- “**Күршеләр**”**уены.**Уенчыларга җөмләләр язылган карточкалар бирелә.Үзләренең күршеләре турында **сөйлиләр.1 нче укучы.Айрат китап укымый.Азат дәрескә бармый.Алсу китапханәгә йөрми.Әнәс дусты белән сөйләшми.2не укучы. Илгиз рәсем ясамады.Азат авылга кайтмады.Айгөл дәфтәр алмады.Алия әнисенә карамады**. Сорау *: “Күршеләрнең кайсы ягын сиздегез?” Укучы : -Фигыльләргә игътибар иттек.Инкяр итү,төрле заманда килгәннәр.-Сез күршегез турында ни әйтер идегез? - Укый,бара,сөйләшә,ясый,кайта,ала,карый.-Ул күршеләргә нинди киңәш бирер идегез? – Айрат китап укы.Азат дәрескә бар.һ.б.- Сез ни эшлисез? – Эш кушабыз.-Мондый фигыльләр ничек атала? –Боерык фигыль .* **Әлеге уен заманнарны кабатлап,боерык фигыльгә кергәндә отышлы.**

# “Парыңны тап” уены

- Төркемдә һәр укучының пары бар.,тик парлар билгеле түгел.Сораулар биреп ,парын табарга тиеш.Укытучы балаларга сәяхәткә чыгарга тәкъдим итә.Катнашучыларның бурычы-үзенә юлдаш табу. Бирем: сүзләр бирелә,үзенчәлеген аңлап берләшәләр.**Сүзләр: укыды,языгыз,яза,ясадым, укысын,төзи. П**арын дөрес тапса,берләшкән сүзләрнең номерларыннан хәрефләр кушылмасы барлыкка килә. **ФИ ГЫ ЛЬ**

# “Мәкальләр аланы”

- **- Беренче тукталышыбыз – «Мәкальләр аланы».**
- Менә бу мәкальләрне игътибар белән укып карыйк әле. Нинди фигыльләр җитми икән?
- - Эш кешене …, ялкаулык … .( төзәтә, боза)
- -Сүзең белән … - эшең белән … .(мактанма, мактан)
- - Бүгенге эшне иртәгәгә … (калдырма)
- - Беләге юан берне … , белеме юан меңне … .(егар)
- - Без капчыкта … .(ятмый)
- -Ялган сөйләсәң - …,
- Дөресен сөйләсәң … (тотылырсың, котылырсың)
- (бу мәкальләр тактада язылган була; укучылар фигыльләрне рәт буенча тактага чыгып язалар)

# “Заманнар “

- **Өченче тукталышыбыз – «Заманнар».**
- -Фигыль нинди заманнарда килә?
- - Үткән, хәзерге, киләчәк.
-
- -Үткән заман хикәя фигыль нәрсәне белдерә һәм нинди сорауларга җавап бирә? (*Үткән заман хикәя фигыльләр сөйләгән вакытка кадәр үтәлгән яки үтәлмәгән эшне белдерәләр*)
- - Хәзерге заман хикәя фигыль нәрсәне белдерә һәм нинди сорауларга җавап бирә?
- - Киләчәк заман хикәя фигыль нәрсәне белдерә һәм нинди сорауларга җавап бирә?( *Киләчәк заман хикәя фигыль киләчәктә үтәләчәк яки үтәлмәячәк эшне белдерәләр*.)

- Дәреслекнең 89 биттәге 226 нчы күнегүне эшлибез. Фигыльләрне таблицада күрсәтелгәнчә төрләндереп язарга. *(Һәрбер укучыга аерым сүз бирелә)*
- Укы,сөйлә, кайт, яшә,тор, кил, әйт, ю, көл, тара, кара.

Ә хәзер бирелгән фигыльләр буенча исемне белдерүче сүзләрне табарга кирәк.

- Оча, куна, сайрый, корт чүпли, оя ясый, бала чыгара … (кош).
- Чаба, кешни, узыша, йөк ташый … (ат).
- Шуыша, чага, урала, ысылдый … (елан).
- Йөзә, саклый, ашый, йоклый, эзли,өрә … (эт).

# “Хаталар сараенда”уены

Бу бәйге сезне хаталар сараена алып керәчәк.. Татар телендә без өйрәнгән кагыйдәләрне искә төшереп, сез аларны төзәтергә тиеш. Бу хаталар барысы да фигыльгә кагылышлы.(Конвертта биремнәр таратыла)

- 1. Мин быел 4нче сыйныфта укый.
- 2. Яз башлана 1нче мартта.
- 3. Тиздән каникуллар башланырга.
- 4. Аю өйдә яши, урманда яшәми.
-
- 1. Мин әниемне 8март беләң котлый.
- 2. Укулар башлана 1нче сентябрьдә.
- 3. Яз көне табигать уянырга.
- 4. Песи урманда яши, өйдә яшәми.
- (Командаларга вакыт бирелә һәм җаваплар тыңлана. Экранда дөрес җаваплар чыгып, тикшереп барыла, жюрига сүз бирелә)

# “Башваткычлар урамы” уены

- **“Башваткычлар урамында” – На улице головоломок**
- Без хәзер башваткычлар урамына аяк басачакбыз. Бу бәйгене узар өчен бик зирәк, тапкыр булырга кирәк. Әлеге урамның һәр почмагында сезне башваткычлар көтеп тора.
- **1.** Монда нинди фигыль кирәк?(укырга)
- Күп белер, акыллы булыр өчен  китаплар ... кирәк.
- 2. Нинди сүз артык?(бәйрәм)
- Котлый, ашый, эчә, бәйрәм, була
- 3. Бу нәрсә?(боз)
- Утта янмый, суда батмый?

# “Гөмбә җыю” уены

- “Гөмбә җыю” уенын хикәя фигыльнең заманнарын өйрәнгәндә куллану отышлы. Кәрзиннәргә хикәя фигыль заманнары языла. “Гөмбә”ләрнең артына төрле замандагы фигыльләр язылган. Укучылар “Гөмбә”ләрне тиешле кәрзиннәргә салырга тиешләр

# Уен технологиясе кулланунның нәтиҗәсе

- Укучыларның күзәтүчәнлек,игътибарлылык,сабырлык кебек сыйфатларын,хәтер һәм зиһенен үстерә, фикерләү сәләте үсеше белән бергә,туган телгә,туган якка мәхәббәт  тәрбияләнә
- Уен аша укытучы укучы белән аралашуны да җайга сала
- Балалар коллективын берләштерүдә ,туплауда мөһим.

# Әдәбият исемлеге

- Әдәбият.

- *1. Гайфуллин В.Г. Педагогик технологияләр // Мәгариф, 2000. – № 4. – Б. 7–10.*
- *2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.*
- *3. Сәмигуллин Г.Х., Баһавиев И.И. Укучыларның проект эше белән идарә итү // Мәгариф, 2004. – № 12. – Б. 2–13.*
- *4. Хайдарова Р.З. Научно-педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан. – Набережные Челны, 2006. – 200 с. һ.б.*

- *Татар телендә*
- *Заһирова Г.Ш. Укыту-тәрбия процессында заманча инновацион компьютер технологияләрен куллану / Г.Ш. Заһирова // Развитие исследовательской компетенции учителя татарского языка и литературы. Сборник статей и докладов. – Казань: ИРО РТ, 2011. – Б.: 65-69.*
- *Татар  теле дәреслекләренә электрон  кушымталар. Методик ярдәмлек / Шәмсетдинова, А.А. Башарова. - Казань*

- *Рус телендә*
- *Ершов А.П. Компьютеризация школы и математическое об-разование / А.П. Ершов // Информатика и образование – № 5, 6. –1992. – С. 3–6. 37.*
- *Симонова И.В. Модели обучения практико-ориентированных учащихся в условиях развивающегося интернет-образования / И.В. Симонова. - СПб.: Изд-во СПбГТУ, 2000. – 99 с.*
- *Талызина Н.Ф. Внедрение компьютеров в учебный процесс научную основу / Н.Ф. Талызина // Сов. педагогика. – 1985. – №12. – С. 34-38.*

# Электрон ресурслар:


- *Научно-исследовательская работа в школе. [Электронный ресурс]: режим доступа: http://rudocs.exdat.com.*
- *Нуруллина Л.Х. Использование современных инновационных подходов к преподаванию татарского языка и литературы [Электронный ресурс]: режим доступа: // conf.knitu.ru: VШ респуб. научно-методическая конференция педагогов общеобразовательных учреждений, преподавателей учреждений среднего и высшего профессионального образования «Интеграция школы и вуза как эффективный инструмент формирования актуальных компетенций учащихся» Казань, 2015. URL: // http://www.conf. knitu.ru рус телендә.*

# Тәмам

*Игътибарыгыз өчен рәхмәт.*